Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Кәкерле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең адресын үзгәртү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2014 елның 19 декабрендәге 46/4 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару тәртибен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының “Иске Кәкерле урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең урнашу урынын түбәндәге адрестан үзгәртергә: 422476, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Кәкерле авылы, Совет урамы, 55 йортны - 422476, Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Иске Кәкерле авылы, Совет урамы, 52 йортка.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Кәкерле урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе директоры урынбасары И.А. Хөсәенова Россия Салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча органнарында юридик затларның Бердәм дәүләт реестрындагы юридик затлар турындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү өчен документлар тапшырганда, мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга тиеш.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе: М.Р. Гафаров